ГЕРОЙ ТАБИБЛАР

Татарстаннан барлыгы 35 медицина хезмәткәре махсус хәрби операция зонасына киткән

> 2

КЕРМӘСЕН ЧИР!

Белгечләр язын авыл кешесенә аеруча игътибарлы булырга киңәш итә

> 2

ГОМЕРЛЕК ТЕРӘК

Дания апа тормыш сукмаклары буйлап Илсуры белән гел янәшә атлый

> 3

АНА ЙӨРӘГЕ

Авырлык килгәндә, үз эченә бикләнмәскә, ничек тә кеше арасына чыгарга көч табарга кирәк икән

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 32 (28999) | Сишәмбе | 7 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

БӘЙРӘМ ҮТСЕН, ХӨРМӘТ КАЛСЫН

8 МАРТ АЛДЫННАН ХАТЫН-КЫЗ КАДЕРЕ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕК

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Иртәгә – гүзәллек, мәхәббәт һәм җылылык бәйрәме. Язның тәүге бәйрәме – Халыкара хатын-кызлар көнен әнә шулай дип атарга яраталар. Аллы-гөлле чәчәк бәйләмнәре, бүләкләр, котлау сүзләре – бу көнне ир-атлар сөйгәннәрен ничек тә сөендерергә тырыша. Ләкин игътибар күрсәтү өчен бәйрәмне көтеп торырга кирәкме? Безнең җәмгыятьтә хатын-кызга кадер-хөрмәт дәрәҗәсе нинди? Бәйрәм алдыннан әнә шул һәм башка сорауларга җавап эзләдек.

Беренче итеп сүзне бәйрәм ияләренең үзләренә бирик. Язучы, журналист Ландыш Әбүдәрова фикеренчә, хатын-кыз бүген дә яклауга мохтаҗ.

– Җәмгыять – бик үзенчәлекле организм бит ул: аның бәхетле, сәламәт булу-булмавы үзеннән тора, табигатьтән түгел. Шуңа күрә дә бүгенге җәмгыятьтә хатын-кызга карата хөрмәт турында гына түгел, гомумән, кеше кадере турында уйланырга кирәк иде. Һәркем үз кадерен үзе генә белеп, үзе теләгәнчә яшәргә хаклы дип яши торгач, кызык хәлдә калдык бит әле: берәүнең дә кадере калмады. Хәзер һәркем хаклы, кешеләр, хаклылыгын исбатларга тырышып күкрәк төя-төя, икенче берәүне рәнҗетүдән, аның өлешенә керүдән дә курыкмый башлады. Бүгенге җәмгыятьтә хатын-кыз мәсьәләсе бер төрле идеология өчен – бишенче тәгәрмәч, икенче бер төрлесе өчен тоткасыз чемодан кебек тоела. Берәүләр, хәл ителгәнгә санап, ул теманы әйләнеп уза, ягъни хатын-кыз сайлауларда катнаша, карьера баскычларында ирләр белән тигезлеккә ирешә, белем алу хокукына ия, тагын ни кирәк? Икенче берәүләр хатын-кызлар эмансипациясеннән (ирек, ягъни. – **Авт.**), радикаль феминизмнан ирләрне якларга кирәк дип чыгыш ясый. Әмма миңа калса, хатын-кызлар бүген дә барыбер яклауга мохтаҗ булып кала. Хатын-кызны бүген харрасменттан (мыскыллау, ягъни. – **Авт.**), гүзәллек турындагы мифтан, өйдәге «икенче смена»дан якларга кирәк. Дөрес, бу проблемалар турында әйтеп тә торасы булмас иде. Әгәр җәмгыятьтә чын мәгънәсендә хатын-кызларга карата кадер-хөрмәт булса…

Заман гүзәл затлары бу җәһәттән ни уйлый? «Татар кызы – 2022» бәйгесе җиңүчесе Энҗе Габдуллинаның фикерен белештек.

– Хәзерге заманда хатын-кызның кадере артты, дип уйлыйм. Чөнки ул үзен үзе кадерли башлады. Мин әниләр, әбиләр буынын үзебез белән чагыштырып карыйм да, хәзер хатын-кыз үзен хөрмәт иттерә белә, дигән нәтиҗә ясыйм. Шундый булырга кирәк тә. Безнең җәмгыять хокук ягыннан да хатын-кызның иреген кысмый. Анысына шөкер итәргә кирәктер. Шуңа күрә ир-ат затыннан кадер-хөрмәт күрергә теләсәк, беренче чиратта, үзебезне үзебез кадерлик. Матди яктан бигрәк рухи халәтне үстерсәк, үзебез өчен тырышсак, үссәк, безгә карата фикер дә тиешенчә дәрәҗәдә булачак. Иң мөһиме, үзебезне пычракка ташлап таптарга ирек бирмәскә, – диде ул. – Миңа калса, хатын-кызга игътибар көн дәвамында кирәк. Бик көчле күренсәк тә, нечкә күңелле затлар бит без. Мин үземә көн саен шаккатып та, гаҗәпләнеп тә куям, чөнки кәеф яшен тизлегендә үзгәрә. Бер карасаң, кызык та, кыен да. Тик безне Аллаһы Тәгалә шундый үзенчәлекле нәфис затлар итеп яраткан бит. Шуңа күрә ир-егетләребез безнең хәлне аңларга тырышсын иде. Алар безгә үз игътибарларын кызганмаса, без дә бурычлы булып калмыйбыз бит. Чөнки тормыш ул – бумеранг.

Үз-үзеңә кадер-хөрмәт димәктән, ул бит күп очракта ниндидер кечкенә, әмма бик мөһим нәрсәләрдән башлана. Әйтик, чәчәкләр. Флорист Алия Фәттахова сүзләренә караганда, бер сәбәпсез, бары үзен сөендерер өчен генә чәчәкләр сатып алучы хатын-кызларның саны елдан-ел арта икән.

Менә бәйрәм диген син! Баксаң, 14 февральдән алып 8 Мартка кадәр аралыкта гаиләдәге низаглар саны да, төшенкелеккә бирелүчеләр дә арта икән. Соңгылары гүзәл затларга бигрәк тә кагыла. Белгечләргә ышансаң, сөйгәненнән үзе өмет иткән бүләкне алмаган очракта яисә бөтенләй бүләксез калганда күп кенә хатын-кызлар үзләрен кирәксез дип хис итә. Бәйрәмнәргә карата мондый мөнәсәбәттән ничек арынырга? Психолог, арт-терапевт Елена Мкртычан, иң беренче чиратта, бәйрәмнәрнең асылын искә төшерергә киңәш итә.

– Бәйрәмнәрнең тарихи контексты онытылып бетте диярлек. Әйтик, 8 Март – матурлык бәйрәме генә түгел, хатын-кызларның хокуклары өчен көрәш бәйрәме. Кемнәндер нәрсә дә булса өмет иткәнче, үзегезгә үзегез бәйрәм ясагыз! Эмоцияләрегезнең, хис-кичерешләрегезнең ниндидер бүләкләргә бәйле булуына юл куймагыз. Мөнәсәбәтләрне дә бәйрәмнәр белән сынамагыз, – дип язган ул «Psychologies.ru» порталында.

– Ә ир-атларның төрлесе бар. Елга бер мәртәбә – шушы 8 Март көнне генә чәчәк сатып алучылар да, әледән-әле сөйгәннәрен сөендерүчеләр дә бар. Гадәттә, аларның саны тигез була, – ди ул.

Ахыры 3 нче биттә >

Сан

SuperJob хезмәте уздырган сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, ел саен **23** февраль һәм **8** Мартка бүләк бирү традициясеннән баш тартучыларның саны арта икән. Әйтик, быел ир-атларның **39** проценты Халыкара хатын-кызлар көненә бүләк тә, чәчәк бәйләме дә алырга җыенмавын белдергән. Өч ел элек бу сан нибары **22** процентны гына тәшкил иткән.

ҺӘРБЕРЕГЕЗ ҖӘҮҺӘРГӘ ТИҢ!



Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Халыкара хатын-кызлар көнен бәйрәм итү уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле хатын-кызлар!

Сезне Халыкара хатын-кызлар көне белән котлыйм!

Язның бу күркәм бәйрәме ягымлы сүзләргә, сөенечле елмаюларга, ихласлыкка гаять бай. Чәчәк бәйләмнәре, бүләк-күчтәнәчләр, тәбрикләүләр – болар сезгә булган олы хөрмәтебезнең кечкенә бер чагылышы гына. Һәрберегез җәүһәргә тиң, кабатланмас һәм бердәнбер! Сез уңган да, җитез дә, хезмәт урынында уңышлар казанырга да, йорт эшләрен башкарырга да, якыннарыгызны кайгыртырга да өлгерәсез, гаилә учагын, йөрәк җылыгызны, сөюегезне өстәп, сүндермичә саклыйсыз.

Хатын-кызларга хас булган шәфкатьлелеккә, юмартлыкка ихтыяҗ һәрчак бик зур. Шуңа да бу тантаналы мизгелләрдә матурлык, тынычлык, Ананың сабыена мәхәббәте гәүдәләнеше буларак гүзәл затларыбызны олылау, аларга соклану хисләре аеруча көчәя.

Туган телебез, мәдәниятебез һәм гореф-гадәтләребезне яратуны күңелебезгә сеңдергән әниебез алдында без мәңгелек бурычлы. Тормышта терәк булган хатыныбыз, күп бала табып үстергән, ятим сабыйларны канат астына сыендырган, үзен шул игелекле эшкә багышлаган аналар чиксез ихтирамга лаек. Россиядә уздырыла торган Укытучы һәм остаз елында, Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында боларның әһәмияте тагын да арта.

Хатын-кызлар төрле өлкәләрдә – мәгарифтә һәм мәдәнияттә, фәндә һәм эшкуарлыкта, сәнгатьтә һәм дәүләт идарәсендә эшли. Бик күпләрегез ирләр белән беррәттән җаваплы вазыйфалар башкара. Хәзерге көндә сез җиңмәслек кыенлыклар юк, дип ышанып әйтергә мөмкин.

Бөек Ватан сугышы авырлыкларын кичкән мөхтәрәм хатын-кыз ветераннарыбызга, сугыш чоры балаларына, шулай ук махсус хәрби операция вакытында бүген Россияне саклаучы солдат һәм офицерларның аналарына, хатыннарына чиксез хөрмәтебезне, теләктәшлегебезне белдерәбез. Хәрби хезмәттәге хатын-кызларга, социаль һәм медицина өлкәләрендә эшләүче, балаларга белем һәм тәрбия бирүче, аларның сәләт-мөмкинлекләрен үстерүче укытучы ханымнарга-туташларга рәхмәт сүзләребезне җиткерәбез. Без сезнең белән горурланабыз!

Кадерле хатын-кызлар!

Сез Татарстаныбыз һәм тулаем дәүләтебез үсешенә бик зур өлеш кертәсез, шул ук вакытта мөлаемлык, назлылык, зирәклек һәм сизгерлек, нәфислек һәм затлылык кебек асыл сыйфатларыгызны җуймыйсыз, гаиләне, рухи-әхлакый хәзинәләрне саклау мөһимлегенә җәмгыятьнең игътибарын юнәлтә киләсез.

Сезгә бәхет, күңел күтәренкелеге, нык сәламәтлек, якты өметләр, иминлек һәм уңышлар телим!

Вазгыять

Табигать кенә уянмый

Зәмһәрир суыклар узды, язга аяк бастык, салкын тиеп авырулар артта калды… дип уйларга да өлгермисең, яз белән бергә бер бәйләм башка төр чирләр дә баш калкыта. Язда сулыш, ашкайнату системалары чирләре, психик, шулай ук салкын тию билгеләре булган авырулар кискенләшә. Әле ничә ел рәттән янәшәбездә йөргән COVID-19 турында да онытырга ярамый.

Медицина белгечләре кисәткәнчә, язгы чорга кергәндә иммунитет шактый какшый, шуңа күрә чир дә авыррак үтә. Моннан тыш, астмадан интеккән кешеләргә аеруча сак булырга киңәш ителә. Сулыш юллары кысыла, бу кеше сәламәтлегенә дә тәэсир итми калмый.

Ашказаны яки эчәк авырулары белән интегүчеләр кышкы-язгы сезонда һава торышы һәм температура үзгәрүенә бәйле рәвештә кыенлык кичерәләр. Шуңа күрә аларга туклануын көйләргә, гастроэнтерологлар белән киңәшләшергә кушалар.

«Стопкоронавирус.рф» сайты мәгълүматларына караганда, узган тәүлектә Россия буенча коронавирусны 11163 кеше йоктырган. Ил буенча караганда, хастаханәгә ятучылар саны кимегән (узган тәүлектә 615 кеше). Барлыгы 9166 кеше сәламәтләнгән. Бу да бер тәүлек элегрәк булган күрсәткечтән 2,6 процентка күбрәк.

Татарстанда вируслы инфекцияләр буенча вазгыять тотрыклы. Роспотребнадзор һәм Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы халыкка иркенәергә киңәш итми. Грипп та, коронавирус инфекциясе дә көн кадагында торган сораулар рәтеннән төшми. Сан теле белән әйтсәк, соңгы тәүлектә коронавирус белән авыручыларның саны 175не тәшкил итте. Күрсәткеч былтыргы саннарга якыная: 20 октябрьдә чирләүчеләр саны 199 булган.

Моннан тыш, «эчәк гриппы» дигән төшенчә белән дә шик уята медицина вәкилләре. Анысы, исеменнән аңлашылганча, ашказаны-эчәк трактын зарарлый. Һавада тамчылар ярдәмендә тарала торган вирус организмга пычрак куллар, көндәлектә куллана торган көнкүреш әйберләр аша күчәргә мөмкин, ди белгечләр. Шулай ук су, сөт, сөт ризыгы, яшелчә, җиләк-җимеш аша да эләгергә мөмкин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Табиб-пульмонолог Олег АБАКУМОВ киңәшләре

- Чирләрдән саклану өчен, көчле иммунитет кирәк. Ул исә туклануыбызга бәйле. Туклану рационында омега-3 һәм D витамины кергән ризыклар булырга тиеш. Даими рәвештә минераль су эчәргә һәм яшелчәләр ашарга киңәш ителә.
- Тагын бер мөһим нәрсә – гигиена. Кулларны юып йөрергә, пычрак куллар белән биткә кагылмаска, тырнак кимермәскә. Авызны терсәк белән каплап төчкерергә. Авыз эче гигиенасы да мөһим.
- Чирләп киткәнсез икән, барлык булган даруларны эчә башларга кирәк дигән сүз түгел. Алай гына иммунитетны ныгытып булмый.

Сүзгә-сүз

Ольга КАЗАКОВА, Россия Дәүләт Думасының Мәгариф комитеты җитәкчесе:

Укытучының дәрәҗәсен күтәрергә кирәк. Сыйныфта фәкать мәктәп җитәкчелеге яки мөгаллим рөхсәте белән генә фото һәм видео төшерүгә кагылышлы закон проекты шуның өчен эшләнде. Укытучыларның хокукларын яклау мөһим. Чөнки балаларны тәрбияләү, белем бирү, хәтта мәктәптәге иминлек тә аларга бәйле.

ТАТАРСТАНДА – ТОРАК ТӨЗЕЛЕШЕ

Республикада 1 млн 28 мең кв. метр торак кулланылышка тапшырылган. Бу – еллык планның 33 проценты.

Коммерцияле торак 598 мең кв. метрлык 81 күпфатирлы йорт	42%
Социаль ипотека 44 мең кв. метрлык 15 күпфатирлы йорт	27%
Шәхси йортлар 386 мең кв. метр	25%



Бала эштә сынала

Казанда һәр өч ата-ананың берсе (36 проценты), балаларны паспорт алгач, ягъни 14 яшьтән эшләтә башларга мөмкин, дип саный. Дүрттән бер өлеше чамасы (23 проценты) – 16 яшьтән, дигән фикердә. 20 проценты балигъ булгач, ягъни 18 яшен тутыргач кына баласын эшкә чыгарырга әзер. SuperJob сервисы, сораштыру үткәреп, шундый нәтиҗә ясаган. Анда 7–16 яшькә кадәрге балалар үстерүче ата-аналар катнашкан.

Шул ук вакытта аларның 9 проценты, һөнәр алмыйча, йөрәк парәсен кайдадыр эшләтүгә кискен төстә каршы чыккан. 4 проценты, киресенчә, 12 яшьтән соң хезмәт килешүе төзергә мөмкин, дип әйткән. Хезмәт белгечләре билгеләп үткәнчә, бигрәк тә әтиләр балаларын алданрак – 15 яшьтән эшләтүне хуп күрә. Ә менә әниләре газизләренең 16 яшьтән генә бил бөгә башлауларын тели.

Карлар эри ашыгып

Татарстанда тотрыксыз һава көтелә: төнлә суытса, көндез эретәчәк. Көчле җир, карлы яңгыр булачак.

Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, иртәгә – 8 мартта Татарстанда циклон хакимлек итәчәк. Аның йогынтысында кар-буран, секундына 15–16 метр тизлектә җил күтәрелә. Көндез һава температурасы −2…+2 чикләрендә тирбәлсә, төнлә −6…−11 градус булачак.

Пәнҗешәмбе – 9 мартта көндез термометрның терекөмеш баганасы +1…+4 градус күрсәтәчәк, төнге сәгатьләрдә суык: −3…−8 градус.

Синоптикларның башлангыч фаразларына караганда, җомга, шимбә – 10 һәм 11 мартта Татарстанда бик җылы һава, көчле җил, карлы яңгыр көтелә. Көндез һава температурасы +3, төнлә −4…+1 градус чикләрендә тирбәләчәк.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТЫНЫЧЛЫК ТӨШКӘ ГЕНӘ КЕРӘ

Глобаль кризис белән зур сугыш алды киеренкелеге кулга-кул тотынышып атлый. Кызганыч, атна саен шундый рухтагы белдерүләр ясарга мәҗбүрбез. Тынычлык һәм иминлек планетаны бик озакка ташлап китте. Безнең өчен иң шомлысы: державаларның үзара каршы тору сызыгы Россиянең көнбатыш чикләреннән үтә һәм атом-төш фаҗигасе белән яный. 2 март көнне АКШ Исландиягә E-6B Mercury идарә итү һәм элемтә самолетын китерде. Ул атом-төш конфликты булган очракта АКШның стратегик су асты көймәләре белән элемтәне тәэмин итә. Ул көймәләрдә атом-төш очлыклы ракеталар урнаштырылган.

Үзен дөньякүләм бердәнбер гегемон дип санаган дәүләт Мәскәү белән хезмәттәшлек итүче дус илләр һәм Россия арасында чөй кагарга тырыша. АКШның дәүләт секретаре Блинкен үткән атнада Урта Азия дәүләтләренә визит оештырды. «Коммерсантъ» бу хакта: «За Среднюю Азию предстоит ожесточенная геополитическая схватка», – дип язды. Вашингтон нинди уңышка ирешер, анысын киләчәктә күрербез. Хәзер геосәяси вазгыять шулкадәр чайкалып тора: кечкенә генә бер хәрәкәт тә базарларны әйләндереп капларга мөмкин. Үткән атнада Берләшкән Гарәп Әмирлекләре ОПЕКтан чыга дигән сүз таралды. Мәгълүмат кырына азга гына чыгып алган шул яңалык нефть бәяләрен түбәнгә ташлады. Бераздан аның дөреслеккә туры килеп үк бетмәве ачыкланды. Ил әлегә ОПЕКта кала, әмма Согуд Гарәбстаны белән әмирлекләр арасында җитди бәхәсләр бара. Дубайда нефть картеле соңгы вакытларда кабул иткән карарлар – җир маен чыгаруны киметү килешүләре әмирлекләрнең милли мәнфәгатьләренә каршы килә дип санныйлар һәм ил эчендә, чынлап та, ОПЕКтан чыгу турында бәхәсләр кыза. Ул бәхәсләргә Вашингтоннан торып ут өстәмиләрдер дип ышанып булмый. ОПЕК көчсезләнсә (әмирлекләрнең аннан чыгуы оешманы нык чайкалдырачак), «кара алтын» бәяләре түбәнәер. АКШ шуңа омтыла да инде. Дубай белән Әр-Рияд арасында каршылыкларның зур бер төене төйнәлеп килә. Ил лидерлары быелның башыннан үзара йөрешүдән туктадылар. Россия өчен күңелсез вазгыять бу.

Эчке базарлар буенча еврокомиссар Тьерри Бретон Европа оборона сәнәгатен хәрби чор моделенә күчерергә кирәклеге турында белдерү ясады. Путин әйтүен әйтте дә ул: «Пушки вместо масла» дигән вазгыять булмаячак», – дип, әмма Көнбатыш нигездә Россиягә каршы коралана. Я җавап бирәсең, я капитуляция ясыйсың, урта юл юк. Дөрес, тагын бер каршылык сызыгы бар. АКШның Аляска штаты сенаторы Дэн Салливан: «Тайваньның Кытай контроленә күчүе дөнья икътисадына бер елга 2,5 триллион долларга төшәчәк», – дип белдерде һәм Тайваньда дөньядагы иң алдынгы ярымүткәргечләрнең 92 проценты җитештерелүен искә төшерде. Тайвань тирәсендә тартыш зур конфликтка әверелерме-юкмы, әйтүе кыен, ләкин әлегә ул Америка коралы көчләрен үзенә җәлеп итеп, Россиянең көнбатыш чигендә киеренкелекне бераз киметә. Әмма Польшаның Гдыня портына гаҗәп күп хәрби техника китерелде. Бу Мәскәү – Киев конфликтын якын киләчәктә зуррак югарылыкка күтәрергә мөмкин.

Россиядә

ДЕРИПАСКА ТӨШЕНКЕЛЕККӘ БИРЕЛӘ

Россия бюджеты быел тотрыклылыгын саклаячак, бюджет дефициты булса да куркыныч түгел. Россиянең рәсми финанс хакимиятләре шулай дип белдерә. Хәтта нефть-газ керемнәре кискен кимесә дә, бюджет казанына елның беренче ике аенда байтак акча керде, диләр. Мәскәүдә бюджетка акча табуның хәйләле адымнарын беләләр һәм файдаланалар. Финанс министрлыгы яңа кагыйдәләр кертте дә гыйнвар – февраль айларында 214,7 миллиард сумлык юань сатты. Акчаны акчага сату сәүдәсе аеруча февраль аенда нык кызды. Юаньнардан 160 миллиард сум сыгып алынды. Валютаны кыйммәткәрәк сату – бюджет керемнәрен үстерүнең иң җиңел ысулы. Февраль аенда доллар 70 сумнан 75кә кадәр үсте, юань да, 4 процентка кыйммәтләнеп, 10,78 сумга җитте. Бер юань һәм бер доллар сумнарны күбрәк бирә дигән сүз бит инде бу. Дөрес, андый отышлы сәүдә импорт товарларының кыйммәтләнүенә китерә. Әмма кыйммәтчелекнең анысы да ахыр чиктә бюджетка акча өсти. Моның өчен халыкның кыйммәтле товарларны күпләп сатып алуы кирәк, билгеле. Әмма ваклап сату сәүдәсе соңгы ун ай дәвамында гел кимүгә бара икән. Росстат реаль кимүнең 10,5 процент булуын әйтә. Шул ук Росстат быел 1 гыйнварга Россия компанияләренең салымнар, җыемнар һәм иминиятләштерү взнослары буенча әҗәте 2,63 триллион сумга җиткәнне дә күрсәтә. Бер ел эчендә салым әҗәтләре 541 миллиард сумга, ягъни 27 процентка үскән. Бәяләрне күтәрәсең – сәүдә туктый, салымнарны күтәрәсең – салым җыю акрыная.

Үзәк банк ел саен гыйнвар аеның икенче декадасында илдән күпме капитал китүе турында отчет бирә иде. Март ае җитсә дә, быел саннар күренми. Күренмәс тә, мөгаен. Икътисад белгечләренең бик үк төгәл булмаган исәпләүләре капитал качуның темплары рекордлы булуын күрсәтә. 250 миллиард доллар дип исәплиләр. Моннан алдагы рекорд 2014 елда булган, 150 миллиард долларны чак кына узып киткән. Элек эре капитал ияләре генә валютаны читкә чыгарса, үткән ел акчасы булган һәркем чит илдә яшерергә тырышты.

Себердә үткән Красноярск икътисад форумында миллиардер Олег Дерипаска, ил 2024 елда акчасыз калыр, дип борчылуын белдерде. Кытайдан кала дөньядагы иң зур алюминий җитештерүче Rusal International PJSC компаниясенә нигез салган олигарх: «Акча хәзер үк бетеп бара, чөнки безне селкетә башладылар», – дип кычкыра. Аны аңлап була: америкалылар Россия алюминиена 200 процентлы пошлина кертте. Ләкин Дерипаска үз компаниясе өчен генә түгел, бөтен ил өчен борчыла. Чынлап та, барысы да яхшы барса, резервлар киләсе ел башына кадәр генә җитәчәк. Чимал бәяләре төшсә, быел ук кыенлыклар башлана ала.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЫШАНЫЧЛЫ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

Тышкы сәясәтнең үзгәрмәс өстенлекле юнәлеше. Россиянең ислам дөньясы илләре белән хезмәттәшлеген әнә шулай бәяләр. Мәскәүдә «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеменең Ислам хезмәттәшлеге оешмасы әгъзалары саналган дәүләтләр илчеләре белән очрашу узды. Мөселман дәүләтләренә без дә таянабыз, алар да безне дус күрә икән.

Искә төшереп үтик: Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, ил башлыгы Владимир Путин кушуы буенча, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркемен җитәкли. Очрашуда 2022 ел нәтиҗәләре һәм быелгы эшчәнлек турында сөйләштеләр.

Мөселман илләре белән хезмәттәшлек – тышкы сәясәтнең иң мөһим юнәлешләренең берсе. Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин, очрашуда катнашучыларны сәламләп, шулай диде. Аның сүзләренә караганда, мөселман илләре Россиягә таяна ала. «Без һәрвакыт иң ышанычлы партнер булачакбыз», – диде вице-премьер. Соңгы өч елда Россия белән ислам дөньясы илләре арасындагы товар әйләнеше 30 процентка үскән. 2022 елда мөселман дәүләтләре Татарстан һәм аның башкаласында узган чараларда актив катнашкан. Сан белән әйтсәк, илнең 59 төбәгеннән һәм дөньяның 64 иленнән 6 меңләп кеше дигән сүз бу.

Аның сүзләрен Россия тышкы эшләр министры Сергей Лавров та куәтләде. Министр әйтүенчә, алга таба да хезмәттәшлекне ныгытуга йөз тотачаклар. Хәзерге вазгыятьтә бу бигрәк тә мөһим. Сергей Лавров сүзләренә караганда, Россия ислам дөньясы дәүләтләре белән һәрвакыт үзара хөрмәт, дуслык һәм гаделлеккә корылган мөнәсәбәттә тора. «Без күмәк Көнбатыш тарафыннан тагылган ультралибераль кыйммәтләрне кире кагабыз», – диде ул.

Үз чиратында Татарстан Рәисе – стратегик күзаллау төркеме җитәкчесе Рөстәм Миңнеханов та мөселман дәүләтләренә хезмәттәшлек өчен рәхмәт әйтте.

– Без мондый рәвештә даими очрашып торабыз. Мондый күрешүләр файдага, – диде ул. – Бүген ислам дөньясы халыкара сәясәт, икътисад һәм гуманитар юнәлештә үз кыйммәтләре булган бергәлек, ә ислам икътисады дөнья икътисадының мөһим өлеше булып тора.

Рөстәм Миңнеханов 2022 елда Татарстан һәм аның башкаласында узган мөһим чаралар турында да әйтте, Болгарда ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы зурлап бәйрәм ителгәнне телгә алды. Сүз уңаеннан, былтыр Төркем 10нан артык зур чара оештырган.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, быел май аенда әһәмиятле чара – «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый җыены узачак. 14 нче мәртәбә оештырыла торган чарага, Владимир Путин кушуы белән, федераль статус бирелде. Сергей Лавров та, Рөстәм Миңнеханов та ислам дөньясы илләре җитәкчеләрен Татарстан башкаласына кунакка чакырды.

Ә Татарстанның Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина, чараның дәрәҗәле, көтелгән һәм әһәмиятле булуына басым ясап, программа белән таныштырды. Мәдәни чаралар да, килешүләр, очрашулар да күп буласы икән. Талия Миңнуллина Казанга киләчәк кунакларны алдан ук кисәтеп куйды: Татарстан башкаласында кызлар да гүзәл, ризык та тәмле.

КӨТӘР КЕШЕҢ БАРЫНДА...

Түземсезлек белән көтәбез! Ютазы районының Кара Зирек авылында яшәүче Фәнүзә Хәсәншина әнә шулай дип өзгәләнә. Улы Райнур өлешчә мобилизация игълан ителгән беренче көннәрдә үк кулына повестка алган. 27 яшьлек егет Әлмәттә «ашыгыч ярдәм» хезмәтендә эшләгән. Бүген ул махсус хәрби операция зонасында медицина хезмәте җитәкчесенең урынбасары вазыйфасын башкара.

«Татар-информ»

«Улым шунда барып эләккәннән бирле болай да эленеп кенә торган йөрәк бөтенләй эштән чыкты. Кадерләп үстергән балаңны ут эченә озатудан да авыр нәрсә юк икән. Болай гел аралашып торабыз. Монда вакытны җиткереп булмый, ди. Бер дә зарланмый үзе. Җәй көне ялга кайтам, ди. Түземсезлек белән көтәбез», – дип күз яшьләрен сөртте ничә айдан бирле баласы өчен ут йотып яшәүче ана.

Фәнүзә ханым белән Республика клиник хастаханәсендә узган чарада таныштык без. Бирегә Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов, Татарстан вице-премьеры Ләйлә Фазлыева, сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин махсус хәрби операциядә катнашучы медицина хезмәткәрләренең гаиләләре белән очрашты. Очрашуга барлыгы 43 гүзәл зат чакырулы иде. 43 хатын-кыз, 43 язмыш, 43 тарих… Аларның күңел түрендә ниләр майтарылуын аңлау өчен күзләренә карау да җитә… Телләрендә бары бер теләк: «Кадерлебез исән-сау әйләнеп кайтсын да дөньялар тынычлансын!» Быел язның иң гүзәл бәйрәме – Халыкара хатын-кызлар көненә дә иң зур бүләк әнә шул булыр иде, дип хыяллана алар.

Түбән Камада яшәүче Альбина Зәйнетдинова 8 мартны көтә. Ник дигәндә, бу көнне ире Руслан һәм аның взводындагы егетләргә дип әзерләнгән гуманитар ярдәм юлга чыгачак.

– Ирем Түбән Кама район хастаханәсендә эшли иде. 27 октябрьдә повестка алды, икенче көнне аны озаттык та инде. Аңа чакыру килгәч, югалып калдым. Көтелмәгән хәл булды. Ирем чик буе гаскәрләрендә хезмәт иткән. Шуңа күрә бу – аның өчен намус эше. Улларыбызны да: «Кыю булыгыз, бернидән дә курыкмагыз», – дип тәрбияли. «Бәлки берәр чарасын күрербез», – дип әйтеп караган идем, тыңлап та тормады. «Юк, мин улларыма нинди үрнәк күрсәтәм аннары», – диде. Улларыбыз бүген, дөрестән дә, әтиләре белән бик горурлана. 6 яшьлек төпчек улыбыз, әтисе турында сорасалар, сүзен: «Минем әти – герой», – дип башлый, – ди Альбина ханым.

Күптән түгел андагы егетләрнең тормыш иптәшләре берләшеп, аларга тепловизор, рация кебек кирәк-ярактан башлап, «УАЗ» машинасына кадәр әзерләгәннәр. Туганнар, дуслар, хезмәттәшләренең дә зур өлеше кергән анда.

– Аллаһка тапшырып, 8 март көнне бу әйберләрнең барысын да җибәрәчәкбез. Ирем белән телефоннан сөйләшеп торабыз. Безнең тавышларны ишетәсе килә аның. 27 ел иңне иңгә куеп яшибез бит. Болай озакка гомердә дә аерылып торганыбыз юк иде, – ди Альбина Зәйнетдинова.

Бөгелмәдә яшәүче Екатерина Вишневская да моңа кадәр бернинди борчу күрмичә, ни дәрәҗәдә бәхетле булуыбызны аңламыйча да яшәгәнбез икән, дип көрсенә. Районның «ашыгыч ярдәм» хезмәтендә фельдшер булып эшләгән ирен хәрби операциягә озаткан ул.

– Башта шок халәтендә калдык, билгеле. Беренче айларда бигрәк тә авыр булды. Көн саен елый идек. Мин хәзер сугыш турында җырлар тыңлый, кинолар карый алмыйм. Дүрт яшьлек улыбыз гел: «Әтием кайда?» – дип сорый. «Ул яралы солдатларга ярдәм итә, аларга укол ясый», – дим. Түземсезлек белән әтиебезнең кайтуын көтәбез, – ди ул.

Екатеринаның каенанасы Надежда Вишневская улы турында сөйләгәндә күз яшьләрен тыя алмады. «Улым оныгым өчен генә түгел, безнең өчен дә үрнәк. Аны озату бик авыр булды. Чакырганнар икән, китәм, диде. Улым белән горурланам. Шундый игелекле эш башкара бит», – дип горурлана ана.

Хәзерге вакытта Татарстаннан барлыгы 35 медицина хезмәткәре махсус хәрби операция зонасына киткән. Шуларның 8е – табиб, 24е – урта медицина хезмәткәре. Моннан тыш, бу тармакта хезмәт куйган тагын 12 кеше махсус хәрби операциягә үз теләге белән киткән. Шуларның 7се – табиб, 5есе – урта медицина хезмәткәре.

Татарстан вице-премьеры Ләйлә Фазлыева сүзләренә караганда, бүген мобилизациягә эләгүчеләрнең гаиләләренә ярдәм, түләүләргә кагылышлы күпсанлы сораулар килеп тора.

– «Кайнар элемтә»гә яки штабка шундый мөрәҗәгать килеп ирешүгә, без район яки мобилизациягә эләккән табиб эшләгән медицина оешмасы белән берлектә моны хәл итү юлларын эзлибез. Болар белән беррәттән аларга шушы дәвалау оешмасы, хезмәттәшләре тарафыннан да ярдәм күрсәтелә, – ди ул.

Татарстан сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин сүзләренә караганда, аларның барысының да эш урыннары сакланачак. «Кире туган якларына әйләнеп кайткач, алар янә үз эш урынына урнаша алачак. Шуңа күрә без бүгенге очрашуга медицина оешмалары җитәкчеләрен дә чакырдык. Көнкүреш мәсьәләләрдә аларның да теләктәшлек итүләрен телибез», – диде министр.

Очрашу димәктән, Айрат Фәррахов мобилизациягә эләккән медицина хезмәткәрләренең якыннары белән мондый очрашуларны ешрак уздырырга тәкъдим итте. «Мондый очрашуларны даими оештырып торырга җыенабыз. Бу күп кенә мәсьәләләрне урында хәл итәргә, фикер алышырга ярдәм итәчәк», – дип өметләнә депутат.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КӘГАЗЬЛӘРЕ БАР МИКӘН?

Яз көннәрендә эпизоотик хәл йогышлы авырулар белән катлаулана. Бу күчмә кошларның, кыргый җәнлекләрнең күчүенә бәйле. Монда беренче чиратта кош гриппы турында сүз бара. Тик белгечләрне ел дәвамында куркыныч тудыра торган Африка дуңгыз чумасы белән бәйле вазгыять тә нык борчый. Чөнки әлеге авырулар бик тиз тарала һәм аларны дәвалап булмый, ул шуның белән дә катлаулы.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Бу хакта Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә дә сөйләштеләр. Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы Алмаз Хисаметдинов билгеләп үткәнчә, Татарстан Россиянең барлык төбәкләре белән тыгыз икътисадый элемтәдә тора. Алардан республикага күпсанлы хайваннар һәм продукция кертелә. Әйтик, узган ел Татарстанга 49 мең баштан артык мөгезле эре терлек китерелгән, шул исәптән 12,5 меңе – чит илләрдән.

– Россиянең башка төбәкләренең һәм тулаем дөньяның иминлеге Татарстан иминлегенә йогынты ясый. 2022 ел йогышлы авырулар буенча, Африка дуңгыз чумасыннан кала, тыныч булды. Кызганыч, әлеге авырудан вакцина юк, шунлыктан башка төр профилактика чаралары күрергә туры килә. Кыска вакыт эчендә безнең республиканың төрле районнарда әлеге инфекциянең 11 чыганагы ачыкланды. Хәзерге вакытта вазгыять тыныч, – диде Алмаз Хисаметдинов һәм яз башыннан йогышлы авыруларны профилактикалау эшен көчәйтергә кирәклеген искәртте.

Россия белән чиктәш илләрдә Африка дуңгыз чумасы таралу турында Россельхознадзор да кисәтте.

– Бөтендөнья хайваннарны саклау оешмасы мәгълүматлары буенча, күрелгән чараларга карамастан, 2023 елда Россия белән чиктәш илләрдә Африка дуңгыз чумасы бик кызу темпларда тарала, – диелә оешманың хәбәрендә.

Язын кош-кортлар арасында кош гриппы да баш калкыта. Әлеге авыру буенча узган ел тыныч узган иде, тик бу әле тынычланырга сәбәп түгел, чөнки дөньяда грипп буенча хәлләр бик киеренке. 2022 елда 70 дәүләт территориясендә 8 меңгә якын грипп чыганагы теркәлгән, 120 миллионнан артык кош юк ителгән.

– Галимнәр әйтүенчә, кош гриппы мутацияләнә. Дөньяда әлеге авырудан башка төр хайваннар кырылу очраклары теркәлә. Бу мәсьәләдә бик уяу булырга кирәк, – диде Алмаз Хисаметдинов.

Ул хәбәр иткәнчә, Татарстан территориясенә аеруча куркыныч авырулар кертмәс өчен, ветеринария идарәсенең һәм Россельхознадзорның республикадагы идарәсе тарафыннан ЮХИДИ хезмәткәрләре ярдәме белән ветеринария-полиция постлары эшли. 2022 елда 24 меңнән артык автотранспорт тикшерелгән, ветеринария законнары таләпләрен бозуның 307 очрагы ачыкланган. Хәзерге вакытта тикшерүләр ике урында алып барыла. Берсе – Казанга Мәскәү ягыннан керү юлындагы Малиновка, икенчесе – Чаллы янындагы Тула-1 посты. Тикшерүне көчәйтү өчен, Алексеевск районында Кама аша күпердә тагын бер пост кирәк.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ничә пост кирәк булса, шуның кадәр куярга әйтте. Ул бу эшләрне Прокуратура, Россельхознадзор һәм район башлыклары белән бергә башкарырга кушты.

– Бу – безнең республиканың иминлеге. Әлеге авырулар зур куркыныч тудыра. Биредә дә профилактика чаралары бик мөһим, – дип белдерде Татарстан Рәисе. Ул шулай ук эре һәм шәхси хуҗалыкларда тиешле аңлату эшләре алып барырга кушты.

Татарстан Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе урынбасары Габделхак Мотыйгуллин әйтүенчә, дуңгыз чумасына каршы чаралар ел дәвамында уздырыла.

– Дуңгыз чумасы буенча һәрвакыт уяу булырга туры килә, – диде ул. – Узган ел кыргый табигатьтәге кабаннарга вирус эләккән иде. Аның бетү-бетмәвен беркем дә төгәл әйтә алмый. Хәзерге вакытта күршедәге Самара өлкәсендә кыргый кабаннар арасында вирус бар. Шуңа күрә куркыныч зур. Бу мәсьәләдә бездә эш алып барыла. Кабаннарны аулыйбыз, шәхси хуҗалыкларда да дуңгызлар санын киметү өстендә эшлибез. Оешмаларга бигрәк тә сак булырга, ябык режимда эшләргә кирәк.

Язын исә кош гриппына аерым игътибар таләп ителә.

– Халык тиздән кош-корт сатып ала башлый, – диде ул. – Без аны гел әйтә киләбез инде. Бу юлы да кабатлыйм: авылларга кош-корт китереп сатучылардан ветеринария белешмәләрен сорарга кирәк. Бер дә булмаганда, машина номерын язып алсагыз яки фотога төшереп калсагыз да ярый. Ләкин бу турыда үзләре белергә тиеш. Кош сатучыларда мондый документ һичшиксез булырга тиеш. Күрсәтүдән баш тарталар икән, димәк, законга каршы килеп эшлиләр.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КАРАМА БУЕНА

Балалар катнашындагы юл һәлакәтләрен киметү, юлда йөрү кагыйдәләрен яхшы белгән яшь буын тәрбияләү. Менә шушы максатларны күз уңында тотучы юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары отрядлары (ЮИД) оешуга 6 мартта 50 ел тула. Яшь инспекторлар ниләр белән шөгыльләнә?

Юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары отрядлары Россиядә 1973 елдан бирле эшли. Оешуга ук, бу хәрәкәткә бөтен ил буенча 14 меңләп отряд кушыла. Хәзерге вакытта Россиянең 85 төбәгендә яшәүче 440 мең бала һәм үсмер, барлыгы 34 мең отрядка берләшеп, яшь инспектор исемен йөртә. Татарстанда исә отрядларның саны 1500 булса, имин юл хәрәкәте сагында торучы бәләкәчләр – 19 мең.

Әлеге отрядлар нигә кирәк соң? ЮИД активистлары Дәүләт автоинспекциясе һәм «Юл хәрәкәте иминлеге» учреждениесе хезмәткәрләре ярдәме белән мәктәпләрдә юлда йөрү кагыйдәләре турында сөйли, балалар белән берлектә юлда хәрәкәте иминлеге рейдлары оештыра, яктылык чагылдыру элементларын тарата һәм аларны дөрес итеп куллану серләрен өйрәтә. Бу отрядларга 8 яшьтән алып 18 яшькәчә балалар һәм үсмерләр кушыла ала. Уен гына түгел бу: яшь инспекторларның хокуклары да, үз бурычлары да бар. Әйтик, алар юлда йөрү кагыйдәләрен яхшы белергә һәм һәрвакыт үтәргә тиеш. Яшьтәшләренә үрнәк булырлык итеп! Яшь инспекторларның беренче ярдәм күрсәтә белүе һәм, әлбәттә, белгәннәрен башкаларга да өйрәтүе мөһим бурычларыннан санала. Рейдка чыккан яшь инспекторларны күрсәгез, туктамый калмагыз.

tatarstan.ru

Яшь инспекторларның уңышлары турында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та белә.

Ә әйткәннәренә колак салсагыз, юлыгыз, һичшиксез, хәерле булыр.

Менә шуларны яхшылап өйрәнгәннән соң, Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүче яшь инспекторлар «Имин тәгәрмәч» конкурсында көч сынаша, белгәннәрен күрсәтә. Казанның 124 нче мәктәбендә 30 елга якын эшләүче яшь инспекторлар отряды өчен бу – мөһим чараларның берсе. Елның-елында алдынгылыкны бирми алар. Остазлары Әдилә Бабаева сүзләренә караганда, балаларның бу шөгыльләре гомер буена җитәрлек тәҗрибә бирүе белән кадерле.

– Юлдагы иминлек – тормышыбызның әһәмиятле өлеше. Гомеребез шуңа бәйле. Балалар моны яшьли аңлап үсә. Күбесенең ЮХИДИ хезмәткәрләренә охшыйсы, хәтта шул юлдан китәсе килә. Билгеле, барысы да бу һөнәрне сайламый. Ләкин алар белән берничә дистә ел эшләгән кеше буларак шуны әйтә алам: яшь инспекторлар отрядында тәрбияләнгән балалар – бүген инде тормышта үз урыннарын тапкан төпле фикерле кешеләр. Ә иң мөһиме – шәп машина йөртүчеләр, – дип сөйләде ул безгә.

Татарстанда «Имин тәгәрмәч» конкурсы соңрак – 1986 елдан гына уздырыла. Беренчесендә катнашучылар Түбән Камада җыела. Бу хакта безгә «Юл хәрәкәте иминлеге» учреждениесенең Казандагы җирле идарәсендә профилактика бүлеге җитәкчесе Любовь Ананьичева сөйләде.

– 2012 елда Казанда яшь инспекторлар өчен ЮХИДИ мәктәбе ачыла. Бераз соңрак аның базасында матбугат үзәге дә эшли башлады. Анда яшь инспекторлар, журналистлар, язучылар белән очрашып, каләм чарлау, микрофон тоту серләрен өйрәнә. Мондый үзәк ачу идеясен «Имин тәгәрмәч» конкурсының Европа дәрәҗәсендәге призеры булган Ралинә Хәлимова тәкъдим итте. Быел ул мәктәпне тәмамлый һәм үзе дә журналистика юнәлешенә укырга керергә нияте, – диде ул.

Любовь Ананьичева сүзләренә караганда, быел юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары отрядларының 50 еллыгы уңаеннан республикада төрле эчтәлектәге һәм форматтагы чаралар узачак. Алар барысы да бер максатка – яшь инспекторлар хәрәкәтен популярлаштыруга, киң җәмәгатьчелекне юлда иминлек тәэмин итү проблемаларына җәлеп итүгә, юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә үлем һәм җәрәхәтләрне киметүгә хезмәт итә.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Бәйрәм үтсен, хөрмәт калсын

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Сәбәп кирәк түгел

«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллиннан ислам динендә хатын-кызларга кадер-хөрмәт турында ни әйтелгәнен сорадык.

– Хатын-кыз ул – Аллаһы Тәгаләнең бүләге. Гаиләдә кыз бала туа икән, ул гаиләгә бәрәкәт, уңыш килә. Ике яки өч кыз үстергән ата-ана турыдан-туры җәннәткә керә, дигән Рәсүлебез с.г.в. Үсеп, кияүгә чыккан кыз бала киявенең ярты иманы була. Бала табып, әни булган хатын-кызның аяк асларында җәннәт була. Күргәнегезчә, диндә хатын-кызларның дәрәҗәсе искиткеч зур. Динебез хатын-кызларыбызны һәрвакыт сөендерергә, аларга игътибар күрсәтергә куша. Шулай булгач, безнең өчен 8 Март көн саен булырга тиеш. Ел дәверендә аларны рәнҗетеп, бәйрәмдә генә бүләк бирү бер дә дөрес гамәл түгел, гөнаһы да зур. Аллаһы Тәгалә хатын-кызның дәрәҗәсен билгеләгән инде. Без дә ул дәрәҗәне хөрмәт итик, – диде ул.

Янә бәйрәмгә әйләнеп кайтыйк. Әйтик, алып баручы һәм өч кыз әтисе Айрат Ильясов өчен 8 Март – иң яраткан бәйрәмнәренең берсе икән. Өйдә бәйрәмнең дүрт сәбәпчесе көтеп тора бит!

– Бүләктән бигрәк игътибар кадерлерәк кебек, минемчә. Олыгая барган саен моңа ныграк инанам. Белмим, тәрбиядән киләдерме инде ул, әмма бер сәбәпсез генә, әйтик, чәчәк бәйләме бүләк итү миңа сәер тоела. Ләйсән белән (җырчы Ләйсән Сөнәгатова. – **Авт.**) очраша башлаганнан бирле шулайрак. Ә менә 8 Мартны бик яратам. Өйдә дүрт кыз булгач, быел барысына да бик файдалы зур гына бүләк алырга булдым, – диде ул. – Элеккеге заман белән чагыштырсак, бүген хатын-кызларны җәннәттә яши, дип әйтә өлкән буын. Шәхсән үзем хатын-кызларга хөрмәт ким, дип әйтә алмыйм.

ГЕРОЙ ХАТЫНЫ

Бер уйлаганда, әлеге язмам белән Америка ачмам кебек. Тик менә кайчак хәтердә күптәнге вакыйгалар яңара да, ниндидер ачыш ясагандай буласың. Безнең яшьлек узган совет чорында Социалистик Хезмәт Герое дигән дәрәҗәле исем бар иде. Әйе, бик дәрәҗәле иде ул, Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем белән янәшә йөрде.

Беркөнне 40 яшьтән узган бер танышымнан: «Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исем турында ни беләсең?» – дип сорадым. Җавап бирә алмады. Мин аны гаепләмим, чөнки соңгы утыз елдан артык вакыт эчендә көнделлекләрдә «Социалистик» дигән сүзнең «с» хәрефе дә калмады һәм совет чорының Хезмәт Геройлары да онытылды.

Ә бит заманында аларның даны бөтен илгә таралды, исемнәре телдән төшмәде. Шундыйларның берсе – хезмәт юлын бульдозерчы булып башлап, «Татнефтепроводстрой» тресты идарәсе җитәкчесе дәрәҗәсенә хәтле күтәрелгән якташым Илсур Шәйхетдинов иде.

Бүген сүзем Илсур абый турында түгел. Геройлар турында язганда-сөйләгәндә без нигәдер аларның хатыннарын онытып җибәрәбез. Безнең халыкта «Ирне ир иткән дә – хатын, чир иткән дә – хатын» дигән әйтеп бар. Дания апа тормыш сукмаклары буйлап Илсуры белән гел янәшә атлый. Кайчак мин аны ирләре артыннан Себергә киткән декабрист хатыннары белән чагыштырам. Аерма шунда гына: Илсур абый Себергә партия, ил чакыруы буенча бара, Себер сазлыклары аша нефть-газ торбалары сала. Ә Даниясе аның ныклы тылы, ягъни таянычтерәге була.

Кызганыч, Илсур абый моннан берничә ел элек бакыйлыкка күчте. Аның белән күрешкәләп яшәгәнемә шатланып бетә алмыйм. Бүген Дания апа белән хәбәрләшеп торабыз, сирәк булса да күрешәбез. Аның язмышы үзе бер гыйбрәт, ачылмаган китап кебек. Күңелдән генә әлеге китапның кайбер сәхифәләрен актарыйк әле. Кайчан сүз башласаң да, Дания апа Илсурының әти-әнисен телгә алмый калмый. Хикмәт шунда: иренең әтисе Гарәфетдин абзый армиягә алынгач, «үлем лагере» дип халык теленә кергән Суслонгерга эләгә. Якташларыма ияреп, анда берничә мәртәбә бардым. Беренче баруымда ук авыл җирлеге башлыгы безгә: «Әйтеп куям, без кеше сөякләре өстеннән атлап йөрибез», – дигән иде. Аның әйтүенчә, Суслонгер лагеренда ачлыктан һәм өшеп-туңып үлгәннәр дистә меңнәр белән санала. Шушы санга Дания апаның булачак каенатасы Гарәфетдин абзый да керә язып калган. «Чыбыксыз телефон» аша аның хатыны Камәриягә: «Ирең үлем хәлендә ята, җай таба алсаң, килеп ал!» – дигән хәбәр ирешә. Камәрия, ике дә уйламыйча, үрәчәле чана тотып юлга чыга. Ике йөз чакрымнан артык араны ничек урап кайткандыр ул, бер Алла гына белә. Ә менә Гарәфиенең ярым үле гәүдәсен өенә алып кайтып җиткерә һәм үзе дә урынга егыла. Шөкер, Гарәфи дә, Камәрия дә әкренләп аякка басалар. Инде берничә ел узып, үзләренә килен булып төшкәч, Камәрия Даниягә: «Кызым, бервакытта да иреңнән калма, гел бергә булырга тырышыгыз», – ди. Аның бу сүзләрен Дания апа үзенә васыять итеп алгандыр дип уйлыйм. Илсуры Себер газының ил өчен никадәр кирәк икәнен аңлап, алны-ялны белми эшләсә, Даниясе аңа ышанычлы терәк була.

Әйткәнемчә, Илсур Шәйхетдинов карьера баскычлары буйлап Себер сазлыкларында күтәрелә. Аны башта – бригадир, аннан – колонна җитәкчесе, бер-ике ел үтүгә – участок башлыгы, аннан «Татнефтепроводстрой» тресты идарәсе җитәкчесе итеп куялар. Җитәкче кешенең хатыны, еш кына, иркәләнүче була бит инде ул. Ә Дания апа: «Илсур үзен дә, мине дә җәлләмәде», – ди. Ул моны елмаеп әйтә әле. «Миңа иң авыр эшләрне куша иде, җитәкче үзе генә түгел, аның хатыны да башкаларга үрнәк булырга тиеш, дип әйтә торган иде», – ди.

Мин аның сөйләгәннәрен, сүз саен «Илсурым» дип әйткәннәрен тыңлап утырам да, андый хатыннар бүген күп микән, дип уйлап куям. Дания апа Илсур бригадасы егетләре өчен ашарга да пешерә, аларның урын-җирләрен, киемнәрен дә юа. Агачтан-агачка бау сузып, аларны киптерә, күмер үтүге белән үтүкли.

Илсур абый кул астында эшләгән Ядкарь Мөхәммәдиев белән даими аралашып, хәбәрләшеп торабыз. Дания апа турында язма әзерләвемне белгәч: «Дания апаны «отдел кадров» дип йөртүебезне беләсеңме соң син?» – диде. Каян белим ди сезнең бөтен серләрне?! Ә әлеге «сер» бик гади икән. Ул елларда Себергә китеп, акча эшләргә теләүчеләр шактый булган. Кеше, яхшырак эш сорап, җитәкчегә бара бит инде ул. Ә җитәкчене, ягъни Илсур абыйны тотуы бик кыен. Андый чакларда эшкә алу мәсьәләсен Дания апа хәл итә икән. Ядкарьдән: «Бу баштаклыгы өчен Илсур абый үзен әрләми идеме соң?» – дип сорыйм. Ә ул: «Дания апа кемнең кем икәнен бер карауда ук сизеп ала иде дә иренә тәкъдим итә иде», – ди. Кадрлар мәсьәләсендә ир белән хатын арасында бер генә тавыш та чыкмаган. Димәк, Илсур абый Даниясенә тулысынча ышанган.

Әле Илсур абыйны эзләп, башка гозер белән дә килгәли торган булганнар. Мәсәлән, берәрсенең кызы кияүгә чыкса, йә малае өйләнсә, туйга кайтып килмичә булмый бит инде. Ә рөхсәт сорарга «нәчәлство» урынында юк. Андый вакытларда да мәсьәләне «отдел кадров» хәл иткән. «Кирәк булгач, кайтып кил, Илсур абыеңа үзем әйтермен», – ди торган булган Дания апа.

Һәр чорның үз баласы була инде ул. Башка шартларда үскән, башка тәрбия алган буынның кайбер гамәлләре бүген безгә бераз сәеррәк тә тоела. Әле мин генә түгел, тайгада үзе черки ашаткан Ядкарь Мөхәммәдиев тә Дания апа турында: «Сазлыкларда, бармак башы хәтле кигәвен-черки арасында бала табып, бер генә дә зарланмыйча гаилә тоткан, көнне төнгә ялгап эшләгән кешегә ничек шаккатмыйсың инде?!» – дип әйтеп-әйтеп куя. Кая ул зарлану?! Дания апа авыр эшне үзе сорап ала торган булган. Мин: «Нигә?» – дигәч, миңа аптырап карап куйды. «Нәчәлник хатыны җиңел генә акча алып ята димәсеннәр өчен», – ди. Улы Маратны тайга уртасында вагонда тапкан ул. Кызы Гөлчәчәкне дә вагонда, Төмәннән Казанга кайтучы поезд вагонында таба язган.

Поездга утыруга авырый башлый Дания апа. Илсуры: «Монда бала таба күрмә инде, зинһар, бераз түз!» – ди. Түзә торгач, болар Татарстанга, Биектау районына кайтып җитә. Станциядә поездан төшәләр дә бүлнискә китәләр. Бу – 31 декабрь, яңа елга санаулы минутлар калган. Ишек кагалар, бер кыз ача да: «Бүген монда берәү дә юк, Казанга барыгыз!» – дип, ишекне ябып куя.

Илсур абый Даниясен култыклап, якында гына яшәгән сеңлесенә алып бара. Болар тиз генә «ашыгыч ярдәм» машинасын чакырталар һәм яңадан хастаханәгә китәләр. Табиблар бала табу вакыты килеп җиткән Дания апаны кире бора алмыйлар. Шулай итеп, район бүлнисенең салкын палатасында Гөлчәчәген таба Дания апа. Бүген

ул, шактый олы яшьтә булса да, балаларын, оныкларын барлап, гаилә тотып яши. Аның күңеленә барысы да сыя. Хәл белергә барасым булса, мин Дания апага алдан әйтеп куймаска кирәк дигән фикергә килдем әле. Бер тапкыр: «Сезнең якларга барып чыгарга исәп», – дип шалтыраткан идем. Көнен дә, сәгатен дә әйтмәдем, ә ул мине өстәл әзерләп көн саен көткән, әле тавык күкәйләре дә җыеп куйган. Кош-корт асрый ул. Ниндидер бик тәмле балык та суыткычта мине көтеп тора икән. Бик уңайсыз булып китте. «Дания апа, җаным, ник шулай мәшәкатьләнәсең? Кара-каршы утырып, чәй эчеп, сөйләшеп алырбыз да – шул җиткән», – дип карыйм.

«Нинди мәшәкать ди ул, энем җаным, очрашу бер шатлык кына ул минем өчен», – ди. Аннан соң: «Кешеләрне бик яратам мин, Илсурым да кешегә яхшы булсын дип яшәде», – дип тә өстәде. Себер сазлыкларыннан Татарстан, Россия аша Европа чигенә хәтле газ торбалары сузган Социалистик Хезмәт Герое Илсур Шәйхетдиновның хатыны башкача яши алмыйдыр инде ул. Якынлашып килүче Яз бәйрәме белән сине, Дания апа!

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе **Глебов** Олег Витальевич **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Хәрби һәм Хезмәт Даны орденнары тулы кавалерларының Татарстан Республикасы иҗтимагый хәйрия оешмасы шәрәфле рәисе **Мостюков** Илдус Шәйхелислам улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың нефть-газ-химия комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татнефтехиминвест-холдинг» акционер җәмгыяте генераль директоры **Яруллин** Рафинат Самат улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Казан шәһәре Совет районының «Советлар Союзы Герое С.Ә. Әхтәмов исемендәге 121 номерлы лицей» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Афонская** Валентина Александровна, илебез машина төзү тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «РариТЭК Холдинг» акционер җәмгыяте генераль директоры **Батыршин** Рафаэль Рим улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары – мәгълүмат-методика бүлеге башлыгы **Әхмәдишина** Лилия Мөгамбәр кызы, массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Инвестнефтехим» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең мәгълүмат-аналитика бүлеге башлыгы урынбасары **Бритвина** Елена Валерьевна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Азнакай муниципаль районы буенча Тымытык авылыннан алты бала анасы (аларның бишесе өч яшькә җиткән) анасы **Шәяхмәтова** Ләйсән Илшат кызы, Арча муниципаль районы буенча Урта Пошалым авылыннан биш бала анасы **Җиһаншина** Рәшидә Габделхак кызы, Казанбаш авылыннан биш бала анасы **Рәхимова** Рузилә Зөфәр кызы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге буенча Киров районыннан биш бала анасы **Абдуллина** Гөлчәчәк Габделхан кызы **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мамадыш шәһәренең «Миләшкәй» 10 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе **Мотыйгуллина** Әлфия Динмөхәмәт кызы, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыятенең «ШАЯН ТВ» башкарма директоры – баш мөхәррире **Сәхәбетдинова** Рамилә Әхмәтзакир кызы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең «9 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе **Шушакова** Любовь Ивановна, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Газиева** Нурания Мөхәммәт кызы, «Транс-Контейнер» гавами акционер җәмгыятенең Горький тимер юлындагы филиалы Лагерь контейнер терминалы башлыгы **Кузнецов** Сергей Викторович, Россия Фәннәр академиясе академигы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе шәрәфле әгъзасы **Сюняев** Рәшит Али улы, конфессияара татулыкны һәм тынычлыкны ныгытуга зур өлеш кертүе өчен протоиерей, Рус Православие Чиркәвенең (Мәскәү Патриархаты) Казан Епархиясе Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Петропавел чиркәве приходы православие җирле дини оешмасы настоятеле **Мирганиев** Ирек Фәрит улы (Святослав), физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Россиянең теннис федерациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасы президенты **Тарпищев** Шамил Әнвәр улы, милләтләр арасында татулыкны һәм тынычлыкны ныгытуга, татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлегенең «Татар мәдәнияте үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе түгәрәк җитәкчесе **Шәрипова** Флюра Әхмәтвәли кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәгълүмат технологияләре, элемтә һәм мәгълүматны саклау идарәсе мәгълүмат системаларын үстерү һәм эксплуатацияләү секторы мөдире **Арсланов** Айдар Тәлгать улына **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Казан медицина көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Гайнетдинова** Светлана Валентиновнага, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Бөреле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы **Медведева** Нина Григорьевнага, «Әлмәт шәһәренең 57 номерлы «Сандугач» балалар үсеше үзәге – балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе **Минһаҗева** Рәйханә Әбүзәр кызына, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган Апае урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Насретдинова** Гөлшат Камил кызына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Кавал урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Павлова** Татьяна Дмитриевнага, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое Дементьев Петр Васильевич исемендәге Үби урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Сердцева** Людмила Петровнага, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Октябрь урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Хәйретдинова** Нина Петровнага, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Саба урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Бариева** Миләүшә Мөбин кызына, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең инглиз теле укытучысы **Бәширова** Резеда Роберт кызына, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының 3 номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең биология һәм химия укытучысы **Варакина** Марина Ивановнага, «Е.Н. Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Габидинова** Гөлчәчәк Мәгъсүм кызына, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 3 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Дулова** Галина Валерьевнага, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Советлар Союзы Герое Семён Артемьевич Уганин исемендәге Матак урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбият укытучысы **Ермолаева** Марина Ивановнага, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Татар Тау Иле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең биология һәм химия укытучысы **Җиһаншина** Зөлфия Равил кызына, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Эзмә урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Мифтахова** Вәсилә Хәмит кызына, Казан шәһәре Киров районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 137 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбият укытучысы **Муллахмәтова** Рәмзия Кәрим кызына, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чуваш Борнае урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе – Түбән Колчура башлангыч мәктәбе башлангыч сыйныфлар укытучысы **Мурзакова** Зоя Михайловнага, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Югары Осланның Советлар Союзы Герое Зиннуров Нәбиулла Шәфикъ улы исемендәге гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Осянина** Галина Николаевнага, Казан шәһәре Вахитов районының «Инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган 39 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Пантелеева** Надежда Константиновнага, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Россия Федерациясе Герое А.Н. Епанешников исемендәге 3 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Смирнова** Ирина Владимировнага, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балык Бистәсенең 2 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле укытучысы **Хәлилова** Гөлүсә Зөфәр кызына, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «2 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы **Цыганова** Елизавета Михайловнага **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әтисе

ХОМЯКОВ Геннадий Александрович

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары белән берлектә эшләүне координацияләү идарәсе контроль бүлеге баш киңәшчесе Фәйзуллина Диана Геннадьевнаның авыр кайгысын уртаклаша.

2023 ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

Язмыш

НИЧЕК ТҮЗГӘН ЙӨРӘК?

Балтач

Һәрчак йөзеннән нур бөркелеп торган бу ханымны күреп, чит-ятлар: «Тормыш юлы бик җиңел булган икән, рәхәттә яшәгән», – дип уйларга мөмкин. Тик аны белүчеләр генә бу тынычлык, сабырлык пәрдәсе артында күпме хәсрәт, күпме кичереш һәм күз яшьләре икәнен чамалый. Күрше Салавычта гына яшәгәнгә, Рәйханә апа Насыйбуллинаның тормыш юлы – күз алдында.



Юкса бала чагы әти-әниле, тыныч-имин үтә, яшүсмер еллары да күңелле хатирәләр белән тулы. Тормыш гел шулай дәвам итәр кебек тоела Рәйханәгә. Балтач урта мәктәбен тәмамлагач, Алабугада тегүчелеккә өйрәнә, ательега эшкә урнаша, инде шәһәр тормышына күнегеп кенә беттем дигәндә, язмышы башка якка борылыш ала. Авылдаш егете – бик чибәр, акыллы, эшчән Нурзадага кияүгә чыгып, авылга кайта. Район үзәгендә ателье булса да, юл йөрү кыен дип, кыз анда бармый, фермага терлек карарга керә. Башта бозаулату бүлегендә эшли, аннан сыер сава. «Эш арасында гына» бер-бер артлы Гөлнара, Эльвира, Илнурлары туып, тормышлары түгәрәкләнә.

Шушы гаилә бәхетенең тәмен белеп, сөенеп кенә яшисе дә. Тик... колхозда алдынгы комбайнчы, шофер булган Нурзадасы гына шешә белән көннән-көн ныграк дуслаша. Шушы «дуслык» аны күп елларга тимер рәшәткә артына алып китә дә инде.

Өч баласын ялгызы үстергән Рәйханә апа: «Хәзер аптырап утырам: ул елларда бөтенесенә ничек җитештем икән», – ди. Шөкер, балалары берсеннән-берсе тырыш, тәртипле булып үсә. Ике кызы да Салавычның иң уңган гаиләләренә килен булып төшә. Уллары Илнур, мәктәп елларыннан каникулларда эшләп, өйдә дә әнисенә һәр яктан терәк булып үсә. 1998 елда армиягә китә. Аны дүрт күзләп көткән әни кешегә 2000 елның җәендә кайгылы хәбәр килеп ирешә. «Илнур Хабаровскида хезмәт итте. Бер зарланмады. Чечен сугышының кайнаган еллары бу. Анда эләгер дип уйламадым да. Бер тапкыр анда кергән булганнар инде, анысын әйтеп тә тормады. Икенчесендә озакка керттеләр. Яшермәде. Кайтырына ярты ел калганда, һәлак булды диеп килеп әйттеләр...»

Хәтерлим әле: үтә эссе җәй иде ул. Шул эсседә унбиш көн кайтты Илнур. Табутын ачмадылар. Мәрхүм бабасы Габдулла абый елый-елый Коръән аятьләре укып озатты үзен...

Улы Чечняда һәлак булгач, Нурзада абыйны вакытыннан алда иреккә чыгаралар. Ярдәмнәр дә шактый була. Тик, кызганычка, бу юлы да ул иң кирәк чагында Рәйханәсенә терәк була алмый. «Салдым» белән арасын өзә алмый. Яшьли кинәт үлеп тә китә. «Ярый әле ике кызым да авылда булды, кияүләрем, кода-кодагыйларым һәрчак ярдәм итеп тордылар», – дип искә ала ул елларны Рәйханә апа.

50 яшенә инде тормышның ачысын-төчесен күп татыган Рәйханәгә 2005 елда язмыш зур бүләк ясый: элекке сыйныфташы Шамил бергә булырга тәкъдим ясый. Аңа ризалык биргәненә бүгенгәчә сөенеп бетә алмый Рәйханә апа. «Без унсигез ел бергә, Шамилгә бүгенгәчә рәхмәт әйтеп яшим. Искиткеч әйбәт кеше булып чыкты ул. Оныгым Айназны да, өлкән яшьтәге әниебезне дә сыйдырды».

Айназ – Рәйханә апаның тагын бер йөрәк ярасы – аягөсте генә авырып, операция өстәлендә вафат булган Эльвирасының улы. Бик тырыш, тыйнак, искиткеч чибәр иде Эльвира. Сыер савучы булып эшләгәндә республика бәйгесендә дә җиңгән иде, соңгы елларда хуҗалык ашханәсендә эшләде, әле дә бик сагыналар үзен. Тормыш иптәше Ленар белән Эльвина исемле бик тә сәләтле кыз үстерәләр, аңа иптәшкә дип балалар йортыннан Айназ исемле энекәш тә алып кайталар. Каенанасы Фирая апа белән дә күпләр сокланырлык итеп, бик килешеп, әниле-кызлы яшәделәр. Ленарның туганнары белән дә бик дус булдылар... Эльвираның үлеме менә шушы гөрләп барган гаилә тормышын челпәрәмә китерде. Бу хәсрәткә каенанасы Фирая апаның йөрәге бер генә ел түзде... Ул да вафат булгач, башлангыч сыйныфта гына укучы Айназ язмышы өчен бик күпләр борчылды. Икенче баласын югалту хәсрәтен җиңәргә Рәйханә апага Айназ таяныч була да инде. Башта әтисе, әбиләре белән ике арада йөргән бала, әтисе кабат гаилә корып, Чаллыга күченеп киткәндә, әбисен сайлый.

– Үзе авылдан китәргә теләмәде. Монда дуслары да күп. Ул – бик аралашучан, актив бала. Быел сигезенче сыйныфта укый. Әтиләре белән гел элемтәдә, алар да кайтып йөри. Моңа кадәр әниебез төп йортта энем Рәшит гаиләсендә яшәде, яше шактый инде, әнине без дә карарга тиеш дип, Яңа ел алдыннан аны үзебезгә алып төштек. Ул янәшәдә булгач, миңа да тыныч... – дип сөйли Рәйханә апа.

Яралы җанына иң зур дәваны диндә таба әни кеше. «Мин генә түгел, авыл мәчетенә берничә ел инде шактый хатын-кыз укырга йөрибез, намазга да, Коръән укырга да өйрәндек, ике төркемдә өйрәнәбез. Тормыш итә-итә шуны аңладым: авырлык килгәндә үз эчеңә бикләнмәскә, ничек тә кеше арасына чыгарга көч табарга кирәк икән», – ди ул.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Газетаның киләсе саны 10 мартта чыга.

ҖЫРЛАП ЯШИ АВЫЛ

Мамадыш

Мамадыш районының Югары Сөн авылында тырыш халык яши. Эшкә дә батыр, ял да итә белә алар. «Сөн бизәкләре» этнографик халык фольклор ансамбле җитәкчесе Гөлсинә Гарипова әйтүенчә, мондый авылдашлар булганда, киләчәккә өмет ныгый. Ник дигәндә, алар җыр-бию аша гореф-гадәтләрне, төрле йолаларны үсеп килүче буынга тапшыра.

– Бу ансамбль 1983 елда оештырыла. Ул вакыттагы колхоз рәисе Ирек абый җырга-моңга гашыйк кеше була. Аның теләге һәм тырышлыгы белән оеша да инде ансамбль. Хатыны белән ул үзе дә биредә чыгыш ясый. Гүзәлия Фәләхова җитәкләгән ансамбль тиз таныла. Оешуның икенче елында ук аларны республика күләмендә күреп алып, телевидениегә дә чакыралар, – дип искә ала Гөлсинә. – Алар, 1987 елда Казанда үткән фольклор фестивалендә катнашып, лауреат исеменә лаек булалар. Шул шатлыктан колхоз рәисе, автобус юнәтеп, коллективны Казанга циркка җибәрә. Хәтта 80 яшьлек абыстай Бәдәр апа да бара анда. Хәзер дә бездә өлкән яшьтәге «кыз»лар бик күп.

Гөлсинә Гарипова әлеге ансамбльне 12 елдан артык җитәкли. Эшли башлаганда ук нинди җаваплылык алганын яхшы аңлый ул. Шуңа да сынатмаска тырыша. Җырларга, биергә оста булган ханымнарны чакыра, аларны сәхнәгә чыгарырлык итеп әзерли. Бүген 21 хатын-кыз һәм ике ир-егет, бик теләп, шушы ансамбльгә йөри, ди.

– Безнең уен кораллары да гадәти түгел. Ансамбльдә ярма ярдыргыч, тукмак, гөбе, чуен, комган, сепаратор тәлинкәләренә кадәр аваз чыгара. Этнографик юнәлешне алгач, без онытылып барган гореф-гадәтләрне барлауны максат итеп куйдык. Эшне экспонатлар җыюдан башладык. Әле дә эзләнәбез, кызыксынабыз, – ди Гөлсинә. – Әле менә шушы арада сандыкларны барлый башладым. Хәзер бит инде өйләрдә сандык юк. Элек әниләр кияү йортына сандык белән барса, хәзер комод алып киләләр. Йоланың әнә шулай заманчалашуына күңел әрни. Өйдән-өйгә кереп, сандык җыям. Кемнәрдер аны келәттә, кайберәүләр чормада, чоланда саклыйлар. Урамда яңгыркар астында ятканнары да бар. Мәдәният йортыбыз ике катлы булгач, җыяр урын җитәрлек. Ансамбльнең музеен оештырырга да ниятебез бар.

Гөлсинә – мәдәният йорты җитәкчесе дә. Авылдагы бер генә чара да ансыз узмый. Идеяләре бик күп, авылдашлары һәрберсен күтәреп ала. Әйтик, 87 яшьлек Рабига апа ялындырып тормый, кирәк булганда бии дә, җырлый да. Шушы яшьтә дә кызлар кебек җиңел итеп биеп кара әле син!

– Бу ансамбль миңа бик кадерле, якын. Шуның белән яшим. Эшли башлаганда кияргә күлмәгебез дә юк иде. Күрше авылдан алып торгаладык. Тик кешедән гел сорап тору да уңайсыз. Уйладым да өйдәге сыерны сатарга булдым. Ирем Радик та каршы килмәде. Сыерны 35 мең сумга сатып җибәрдек. Шуның акчасына 18 кешегә күлмәк тектердек. Салмый кидек без аларны. Шул чакта кая гына йөрмәдек. Нинди бәйге турында ишетәбез, шунда чыгып китәбез, – ди Гөлсинә. – Юа торгач, күлмәкләр искерде. Бер елны авыл җыенында район башлыгыннан ансамбль өчен күлмәк сорадым. Ул шунда ук: «200 мең сум җитәме?» – диде. Нәтиҗәдә яңа күлмәкләр тектереп кидек. Инде кыяфәтләребез дә ыспайлангач, яңадан төрле бәйге-фестивальләрдә катнаштык. Бераздан безне Бөтендөнья татар конгрессы аша Татар мәдәни ресурс үзәге эзләп тапты. Кеше ышанмаслык хәл: алар безне баштанаяк киендерде. Туфли, калфакларга кадәр алып биреп, матур күлмәк-камзуллар тектерделәр.

Гөлсинә Гарипова дәвамчылар турында да кайгырта. Мәктәптән-мәктәпкә йөреп, укучылар белән очрашулар оештыра, гореф-гадәтләр турында сөйли. Мәдәният йортында да төрле чаралар уздырып, балаларны җәлеп итәләр. Инде ансамбльнең бер тармагы булып, балалар «Әйлән-бәйлән» фольклор төркеме оешкан. Бирегә йөрүчеләргә – 13–14 яшь. Гөлсинә шушы балаларга үзләре белгәнне тапшырып калдырырга тырыша. Тиздән үзләре дә гаилә корачак бит алар, ди. Әнә шуңа да авылда төрле йолаларны торгызалар. Яз килгәнгә шатланып, «карга боткасы» пешерәләр. Кыш «Олтан салу» күренешен күрсәткәннәр. «Кич утыру» йоласын да яңартканнар. Кыш буе бер-берләренә кунакка барып, шунда җырлап-биеп, кул эшләре белән мәш килгәннәр.

– Бөтен өмет – балаларда. Алар белеп үсмәсә, күңелләренә салып куймаса, безнең тырышудан файда юк, – ди Гөлсинә. – Җәй көне «Урам бәйрәме» ясыйбыз. Атна саен бер урамга чыгабыз. Читтә яшәсәләр, чакырып кайтарабыз. Бик күңелле үтә бу чаралар. Без бер генә ай – рамазан аенда гына ял итеп торабыз. Аннан соң тик торган юк. Мин дәшми торсам, ансамбльдәгеләр үзләре килеп җитә. Сүз уңаеннан, безнең җырларыбыз башкалардан аерыла. Элек ничек башкарганнар, шулай итеп яңгыратырга тырышабыз. Күбрәк үз авылыбыз кешеләре язган җырларны башкарабыз. Үзебезнең як йолаларын яңартабыз. Ансамбльнең халыкка җиткергән 15 йоласы бар. Хәзерге вакытта санамышлар җыя башладык. Ырым-шырымнарны да барлыйбыз.

2021 елда «Сөн бизәкләре»нә халык ансамбле исеме бирелә. Түбән Яке мәдәният йортындагы чыгышларыннан соң тапшыралар аны.

– Авыл җирендә эшләүче шундый коллективыбыз булуга бик шатланам. Күңелемә туры килгән эш булганга, шулай рәхәттер миңа. Авылдашларым да хөрмәт итә. Нинди генә гозер белән килмә, тыңлыйлар. Аларга чиксез рәхмәт, – ди Гөлсинә. – Туган якта бәхет таптым, дип минем кебекләр әйтәдер ул. Читкә китмичә дә, матур итеп яшәп була икән бит. Бар максатым – гореф-гадәтләрне саклап, аны яшь буынга тапшырып, халкыма хезмәт итү. Канат куеп үсендереп торучы тамашачыбыз барында, без әле югалмыйбыз!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

РУНГА УРМАН ҮСТЕРӘ

Буа

Район үзәгеннән 9 чакрым гына ераклыкта урнашкан Рунга мәктәбе турында, урман үстерә, дип кенә әйтү бик аз, әлбәттә. Үзләре төзегән дендрарийны (бу бакчада күп кешенең күзе күрмәгән, колагы ишетмәгән затлы агач-куаклар үсә), питомникта үрчетелгән декоратив агач-куак үсентеләрен, аларны сатып, мәктәпкә килгән файданы исәпкә алсак, туган җирне бизәүчеләр, дип әйтергә кирәк бу укучылар хакында.

Өчьяклы килешү

Мәктәп директоры Олег Дворцов, районга килгән кунаклар да Рунганы урап узмый, мәктәп җитәкчеләре өчен семинарлар да еш үткәрелә, дигән иде. Шулайдыр, эшләре дә, күрсәтерлек әйберләре дә җитәрлек булып чыкты. Казан аграр университеты профессоры Харис Мусин: «Рунгада өчьяклы килешү белән эшли торган яшь урманчылар мәктәбе республикада беренче булып төзелде. Фәнни юнәлештә эшләүче мондый мәктәп башка юк әле», – дигән иде. Аның оештырылу тарихы да гади генә, Буа районының бүгенге башлыгы Ранис Камаретдинов белән бәйле. Башкарма комитет җитәкчесе булып эшләгән чорда ул урман белгечләренә үз фикерен әйткән. Кыскасы, моңа кадәр килешүләр мәктәп белән урман хуҗалыгы арасында гына төзелгән. Хәзер исә аларга аграр университет та кушылган. Югары уку йортының бу исемлеккә керүе аңлашыла торгандыр дип уйлыйм. Төп сәбәбе – яшьләрне урман хуҗалыгына тарту. Яшеренбатырын түгел, соңгы вакытларда балалар бик зур тизлектә «асфальтлаша» башлады. Харис Мусин әйтүенчә, хәтта урманчылар буыннан-буынга династия булып яшәгән нәселләрдә дә бу һөнәрнең юкка чыга баруы гадәти хәл икән.

Ә менә Рунгада моннан дүрт ел элек төзелгән яшь урманчылар мәктәбе үзенекен эшләгән. Бүген зур булмаган авылдан әллә ничә укучы аграр университетта укуын дәвам иттерә. Әзерләнүчеләр дә бар. Бу җәһәттән без 11 сыйныф укучылары Ульяна Комиссарова һәм Дарья Самаркина белән сөйләшеп алдык.

– Без бит – авыл балалары. Кечкенәдән эшләргә өйрәнгән. Яшь урманчылар мәктәбен бик шатланып көтеп алган идек, әмма шул чаклы яратырбыз дип уйламадык та. Орлыклар әзерләп, питомникта затлы агачларның үсентеләрен үстерә башлагач, горурлык хисләре дә уянды. Без чын белгечләр кебек хәзер. Сорашалар, кызыксыналар. Авылда укучылар булмаган гаиләләр дә бик күп. Аларга да булышабыз. Район үзәгендәге паркларга да без үстергән үсентеләрне утырталар, – диеште кызлар.

Кызларның икесе дә аграр университетка барырга җыена. Алар өчен бу – хәл ителгән мәсьәлә. Авырлыклардан да курыкмыйлар. Урманнарны үстерүгә, саклауга багышланган бәйгеләрдә катнашып, өйрәнеп беткәннәр инде. Рунга мәктәбе Татарстан буенча Россия күләмендә оештырылган ярышларда призлы урыннар яулаучы бердәнбер уку йорты икән. Республика бәйгеләрендә исә һәр укучы диярлек катнаша. «Идел аръягы урманнарын саклыйк!» дип аталган бәйгегә әзерләнгән гамәли эшләрдә, картиналарда, рәсемнәрдә ниләр генә сурәтләнми дә нинди генә язмышлар күрсәтелми. Аларның күбесе район үзәгендәге класстан тыш эшләр үзәгенә күргәзмәгә куелган. Мәсәлән, бер картинада браконьерлар соңгы агачны кисеп маташа. Гаҗизлектән нишләргә белмичә урманчы басып тора, ә рәссам, ашыга-ашыга, әлеге агачны истәлеккә сурәткә төшерә. «Рунга» мәктәп урманчылыгы җитәкчесе, биология һәм химия укытучысы Альбина Алексеева әнә шундый фаҗигале хәлләрне булдырмас өчен тырыша да инде.

– Рунга мәктәбендә 56 бала укый. Барысы да – яшь урманчылар. Баштарак үзләре теләгән укучылар гына йөри башлаган иде. Әмма, кызыксынып китеп, калганнары да бик тиз тартылды, – ди ул. – Былтыр агачларны үрчетү максатыннан кисәргә бер сыйныф укучыларын гына алган идем. Быел инде, безгә дә өйрәтерсез әле, дип башкалар да йөдәтеп бетерде. Барысының да беләсе килә. Югыйсә үзенә күрә мәшәкатьле хезмәт инде ул. Түтәлләрне йомшартасы, күчереп утыртасы бар. Микроскоп аша күзәтеп, төрле паразитларны ачыклыйбыз, аннан авырулардан дәваларга кирәк. Орлыкларның сортларын тикшерәбез. Бик күп вакытны алса да, берсенең дә китәсе килми. Быел менә виноград куакларын кисәргә өйрәтермен дип торам. Шунысы рәхәт: практик эшләр өчен үз бакчалары бар. Мәктәптән өйрәнеп кайталар да өйдә үзләре эшләп карыйлар. Һәрберсенең бакчасында туя агачының төрле төрләре, барбарис кебек куаклар үсә. Ландшафтны да төрлечә төзеп карыйлар. Әти-әниләре үсентеләрне үзләре килеп ала. Башта авылдашларга гына өлеш чыгарган идек. Хәзер инде сатабыз. Башка җирләрдән дә килеп алып китәләр. Шулай итеп, мәктәпкә матди яктан да ярдәм итәбез. Иң мөһиме, Буа урманчылыгының урманчы-җитәкчесе Илнар Гатауллин белән гел элемтәдә торабыз. Балалар абыйларына охшарга тырыша, үрнәк ала, аның кебек көчле рухлы буласылары килә.

«Дед»

Көчле рухлы дигәннән, әле очрашканчы ук «дед» сүзе еш ишетелгәч, мин инде урманнар хуҗасын шактый гына олы яшьтәдер, ахры, дип уйлаган идем. Урта яшьләрдәге ир-ат булып чыкты Илнар Гатауллин, җитмәсә, Харис абыйсының укучысы да икән. Бу кушаматны да аңа инде укыган вакытта ук остазы таккан. Сәбәбе дә бар: һәр эшкә кулы ятып торганга, ышанычлы, лидерлык сыйфатлары булганга күрә. Илнар Илдусович остазы сүзләрен кабатларга ярата. «Урман – эш урыны түгел, күңел халәте». Димәк, очраклы кеше монда эшли алмый дигән сүз бу.

Музей кебек

Рунгадагы яшь урманчылар эше бакча һәм питомник белән генә бетми икән әле. Китәр алдыннан без Александр Алексеев җитәкләгән рәсем сәнгате һәм технология кабинетына кердек һәм таң калдык. Төбәк музееннан бер дә ким түгел бу. Яшь урманчылар агач үстереп кенә калмыйлар, эшләрен сәнгать өлкәсендә дә дәвам иттерәләр икән. Монда аларның агачтан уеп ясалган хезмәт җимешләре куелган. «Дөрес, кызыксынучылар кимегәннән-кими бара, – дип зарланып та алды укытучылары. – Әмма бар әле. Шөгыльләнергә генә кирәк. Соңгы елларда мин күбрәк милли әйберләр темасына күчтем. Тарихны өйрәнгән кеше аңлый: балалар берни белми кебек тоелса да, әби-бабалары ясаган әйберләрне бик тиз үзләштерә, чөнки ул аларның канына сеңгән».

Менә шул вакытта Буада яшәүче кайбер чуаш балаларының Рунгага килеп укулары аңлашыла төште кебек. Бу авылда һәр гамәл табигатьне саклау белән бергә милли гореф-гадәтләрне, телне саклауга да корылган икән. Югыйсә баштарак мондый күренеш заманасына күрә гайре табигый кебек тоелган иде. Әти-әниләр, киресенчә, балаларын зур бистәләрдә, шәһәрләрдә укытырга тырыша бит. Димәк, Рунга мәктәбенең үзенә тартып тора торган сере, көче бар. Монысы, бәлки, тәртип, яхшы белем белән бергә шул матур бакчага да, тарихи эзләргә дә бәйледер?!

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5332 данә
Гомуми тираж – 15281 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 232

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+